

Кече Ватан - ул безнен зур, колач житмәс Туган илебезнен бер кисәкчеге. Туган илгә, Ватанга мәхәббәт кече Ватанннан башлана. Ватан - чонки анда йорәгебезгә якын туганнарыбыз яши. Кечкенә Ватан vзенен vзенчәлекле кыяфәте, vз матурлыгы белән, балачакта, балачак жанынын гомерлеккә истәлекле тәә-сирләре вакытында кешегә кvренә, һәм анын белән, бу аерым һәм шәхси Ватан белән, ул еллар узу белән шул зур Ватанга бара...

Шулай Шамиль Загидулла улы Сюняев белән дә. Ул Атюрьево районынын Татар Велязьма авылында гади хезмәт гаиләсендә туып vскән. Анын бабалары һәм әтиләре мәнге жир белән бәйле булганнар. Балачагы бу почмакнын болыннары һәм кырлары арасында, анын кечкенә һәм бик тыйнак табигате йогынтысы астында vтә. Туган кинлекләрдә йорv, чиста Лячи елгасында балык тоту - анын һәр почмагы хәзер дә хәтердә һәм кадерле.
28 июльдә Шамиль Загидулла улы vзенен 70 яшьлек юбилеен билгеләп vтә. Нәкъ менә туган якка булган мәхәббәте аны, vз вакытында, монда урнашырга, гаилә корырга, йорт тозергә мәжбvр итә. Ә бит, башка кvпләр кебек, шул исәптән анын абыйлары һәм апалары кебек, vз бәхетен ерак шәһәрләрдә, мәсәлән, башкалабыз Мәскәvдә эзли алыр иде. Һәркем дә туган һәм vскән жирне сайламый, ә ул сайлый.
Шамиль Загидулла улы ерак яшь чагында авылдан китәргә батырчылык итмәвенә бер дә vкенми. Монда анын ата-бабалары яшәгән, монда анын балалары туган һәм vскән, монда анын оныклары каникулларга рәхәтләнеп киләләр; анын тормышы бәхетле килеп чыккан дип саный ул.
Ерак 1953 елда Шамиль Загидулла Ибрагим улы белән Зәйнәб Усман кызы Сюняевларнын кvп балалы гаиләсендә дvртенче топчек бала булып туа. Әтисе - Боек Ватан сугышында катнаша; фронттан кvрv буенча инвалид булып кайта, ягъни сукыр кайта. Шуна кvрә Шамиль кече яшьтән туганнары белән йорт хужалыгында эшли, ә әнисе гомер буе райпода хезмәт итә. Ата-аналары vзләре дә эш соючән кешеләр булганга, балаларны балачактан ук хезмәтне яратып башкарырга ойрәткәннәр. Ә балалар хужалыкта әти-әниләренен беренче ярдәмчеләре булганнар.
Борынгыдан ук авыл гаиләләрендә кvп санлы терлекләр һәм яшелчә vстерv очен зур бакча тотканнар. Сюняевларнын да шулай була. Атюрьево мәктәбен тәмамлаганнан сон, Шамиль СПТУда укый. Хезмәт стажын да Атюрьеводагы Пластмасс цехында башлый. Аннары ул Сельхозтехникага (авыл хужалыгы техникасында) шофер булып эшкә кvчә. Әмма озак эшләми, шул эш урыныннан армиягә алына. 1973-1975 елларда Архангельск олкәсе автобатында лаеклы хезмәт итә: оенә сержант дәрәжәсендә кайта. Хезмәттән кайткач, ул фермада эшләвен дәвам итә. Биредә 2000 елга кадәр транспортерчы вазифасында намус белән эшли. Ә пенсиягә чыкканчы, сонгы уноч ел дәвамында,

халыктан сот жыя. Үзенен атында ул иртә таннан урамнар буйлап йори һәм икешәр-очәр рейс ясый: мичкәләр сот белән тулган саен, ул аларны май заводына алып китә. Аннары янадан жыюны дәвам итә, жәйге озын коннәр вакытында шул ук эшне кичен дә башкара. Шамиль Загидулловичнын гомуми хезмәт стажы 43 елны тәшкил итә.
Гаилә тормышына килгәндә, Шамиль Загидулла улы 1980 елнын козендә Усть-Рахмановкада туып-vскән сойкемле кызга ойләнә. Нажия Сафиулла кызы анын тормыш юлдашы була. Хатыны ботен хезмәт стажын сәvдәдә эшләvгә багышлый. Ирле-хатынлы алар дус-тату 43 ел яшиләр; кызларына бәхетле гаилә тормышын vрнәк итеп кvрсәтәләр. Бу бәхетле никахтан ике кыз туа - Румия белән Наилә. Алар хәзер инде vз гаиләләрен булдырганнар һәм әти-әниләренә биш онык бvләк иткәннәр. Оныклар зур рәхәтлек, шатлык белән әбиләре белән бабайлары янына кунакка киләләр һәм буш вакытларын аларда vткәрәләр. Жәйге каникулларда икмәкле-тозлы хужалар йорты балалар тавышы белән тула һәм тирә-як та жанланып китә. Бу кvренеш хужаларны шатландыра һәм аларнын яшь вакытларын хәтерләтә. Ә бит кызлары да шулай ук vскәннәр: йорт-ны vзләренен янгыравыклы колvләре белән тутыра торган булганнар.

*Наилэ НАСЫРОВА эзерлэде*